**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Түбән Биш авыл җирлеге Советы**

# К А Р А Р

**24 .06.2024 ел** **№ 132**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2014 елның 05 февралендәге 116 номерлы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 34.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 29 апрелендәге 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәнең 35.1. статьясындагы 10 өлешенә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Советының 2014 елның 05 февралендәге 116 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр кертергә, беренче тәкъдимне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Максатлы укыту турында килешү төзү конкурсында катнашу хокукына Россия Федерациясенең дәүләт телен белгән,тиешле дәрәҗәдәге һөнәри белем алучы һәм укуны тәмамлаганнан соң хезмәт мөнәсәбәтләре барлыкка килүгә китерә торган укучы яки башка килешү буенча йөкләмәләре булмаган гражданнар ия.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

**Түбән Биш авыл җирлеге башлыгы урынбасары** **М.М.Мусин**